**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№2** 09.12.2019 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлеге составына керүче Торыш торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенә керүче Торыш торак пунктында гражданнар жыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Торыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларны, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Торыш авылында су скважинасын ремонтлау
- Торыш авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- Торыш авылы мәдәният оешмаларының ялын оештыру һәм анда яшәүчеләрне хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, Торыш авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Торыш авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру;
- Торыш авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;
- Торыш авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Торыш авылы суларын чыгаруны оештыру;
- Торыш авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Торыш авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру »

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Торыш авылы,Октябрҗская урамы, 24г йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Симәк авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Садертдинов